| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **с. Тюлячи** **БОЕРЫК**

«8» февраля 2024г. № 18

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 21 маендагы 99 номерлы «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 04 августындагы 480-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 9 декабрендәге 124-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 21 маендагы 99 номерлы «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» боерыгына (10.03.2020 № 57 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән боерык белән расланган Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә:

а) 1.2 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә, шул исәптән "Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан" (алга таба - Бердәм портал), тәкъдим, гариза яисә шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;»;

б) 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Гражданның язма рәвештә язылган мөрәҗәгатендә мөрәҗәгатьне җибәрүче органның исеме яки тиешле вазифаи затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме яки тиешле затның вазифасы булырга тиеш, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итү, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), почта адресы яки "Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасы" н кулланганда шәхси кабинетның адресы (уникаль

идентификаторы) (алга таба - Бердәм порталда шәхси кабинет адресы), алар буенча җаваплар, мөрәҗәгатьләрне яңадан адреслау турында хәбәрнамә, шәхси имза һәм дата җибәрелергә тиеш.»;

в) 4.3 пунктта «почта адресы» сүзләрен «адресы (почта адресы, электрон почта адресы яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресы),сүзләренә алмаштырырга;»;

г) 4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5 Электрон документ формасында органга яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгать законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә гражданин үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), электрон почта адресын яки Бердәм порталда шәхси кабинет адресын, әгәр җавап электрон документ формасында җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресын һәм, әгәр җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, почта адресын күрсәтергә тиеш. Граждан мондый мөрәҗәгатькә электрон рәвештә кирәкле документларны һәм материалларны кушымта итеп бирергә йә күрсәтелгән документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.»;

д) 4.8 пунктта «вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә,» сүзләреннән соң «яисә гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча, аннан файдаланганда» сүзләрен өстәргә;

е) 5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм мондый балаларны озата баручы затлар ия.

Бер үк вакытта чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

ж) түбәндәге эчтәлекле 5.8-5.9 пунктлар белән тулыландырырга:

«5.8. Органнарда гражданнарны шәхсән кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә чираттан тыш шәхсән кабул ителү хокукына түбәндәге затлар ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын

һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.

Беренче чираттагы шәхси кабул итү хокукына берьюлы берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килү тәртибендә гамәлгә ашырыла.

5.9. 5.7 һәм 5.8 пунктларында күрсәтелгән гражданнарны шәхсән кабул иткәндә аларның чираттан тыш яисә беренче чиратта шәхси кабул итүгә хокукын раслый торган документ күрсәтәләр.»;

з) 7.1 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) шикаятьне карау нәтиҗәләре һәм аның буенча кабул ителгән карар турында гражданга мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча яки мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы буенча яисә аның белән килешү буенча телдән хәбәр итәргә;»;

и) 12.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.2. Әгәр коллектив мөрәҗәгатьтә җавап алучы билгеләнмәгән булса, җавап үзенең почта адресын, электрон почта адресын яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресын күрсәткән мөрәҗәгать итүчеләр исемлегендә беренче гражданга җибәрелә.»;

к) 12.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.3. Коллектив мөрәҗәгатькә җавап юлламасы турында үтенеч мөрәҗәгать иткән берничә кеше (кул куйган) тарафыннан белдерелгән очракта, җавапның күчермәсе аларның һәркайсына күрсәтелгән почта адреслары, электрон почта адреслары яки Бердәм порталдагы шәхси кабинетлар адреслары буенча җибәрелә.».

2. Әлеге боерык гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Житәкче И.Х. Хәмидуллин